Иске Муса авыл китапханәсе № 22

# Өлешкә төшкән көмеш»

## Сугыш чоры балалары истәлекләре
## электрон презентация




Иске Муса , 2020

**41 дә туганнар**

**Кырык бердә туганнар буыны**
**Утлардан , йотлардан буылып ,**
**Булгандыр торалмый ятылган**
**Чаклар да – аяк – кул суынып.**
**Бала чак ярасын дәвалап,**
**Заманнар яманын куалап,**
**Кырык бердә туганнар буыны –**
**Тормышта яугирләр дәвамы.**
**Кырык бердә туганнар буыны**
**Туктамас урләрдән хуш булып,**
**Бармаслар шатлыктан очынып,**
**Качмаслар хаслыктан пошынып…**
**Кайныйбыз ут – ялкын эчендә,**
**Ятмыйбыз йөрәкне суытып.**
**Ышан ил,**
**Таян , дус ,-**
**Сынатмас**
**41 дә туганнар буыны!**



Кадим Аралбай.

## Кереш сүз.
## Хөрмәтле китап укучылар !

**«Өлешкә төшкән көмеш» исемле** электрон презентациядә Бөек Җиңүнең 75 еллыгына арнап, Башкортстанның Чишмә районы Иске Муса авылында яшәүче 12 тыл ветераннарының, сугыш чоры балаларының хатирәләре тупланды.

Аларның- яшьлеге, кешенең иң матур чаклары иң авыр дәвергә,сугыш елларына туры килгән. Сугыш авырлыгын фронттагы яугирләр генә түгел, ә тылда калган хатын – кызлар да , бала –чагалар да,олы яшьтәге картлар да бер рәттән тигез күтәргән,тылдагы бөтен авыр эш алар иңенә төшкән. Өлешкә төшкән көмеш – ил язмышы иде.

Презентациянең төп бурычы Бөек Ватан сугышы елларындагы сугыш чоры балаларының истәлекләрен киләчәк буынга тапшыру. Бу истәлек-хатирәләрдә күпме күз яше,йөрәк әрнүләре, кайгы –хәсрәт, гаилә фаҗигаләре.



# «Сугыш җимергән язмыш»



**Әхмәтшина Хания Гаяз кызы. 1932 нче елның 2 июнендә Уфа шәһәрендә туган. «Сталинчы» колхозында колхозчы булып эшләгән.**
**Сугыш башланганда 10 яшьлек кыз бала була. Әлеге вакытта Чишмә районы Иске Муса авылында яши.**

Сугыш хатирәләрен Хания Гаяз кызы болай дип искә ала: «...Без ул вакытты Уфада яши идек. 1941 елның май аенда әткәйне Алкинга 2 айлык учениегә алып киттеләр. Ул вакытта безнең әткәй пожарный часть тә эшли иде. Шул китудән этине кабат күрә алмадык». Алкиннан **Гаяз Шәйхетдин** улын туры сугышка озаталар. Гаиләсе белми дә кала.

…Шул хәбәрне әткәй белән бергә учениедә булган иптәше үзенең гаиләсенә хатта язган . (Кызганычка каршы ул кешене Хания Гаяз кызы хәтерләми, әнисе сөйләве буенча гына сөйли)

Хатның азагында :

***« … Гаяздан күп сәләм. Без убыр авызына җиттек.Үтә бәхетегез булса, балалар эти исән кайтсын дип теләк теләсеннәр. Сездән аерылып киткәннән бирле тамакка аш кергәне юк,йокы да юк. Әгәр гомеребез булса, исән – имин әйләнеп кайтырбыз .»***



… Җил - буран уйнатып һавада самолетлар оча, листовкалар ташлап киттеләр .
«… Радиодан сугыш чыккан дигән хәбәрне ишеткәч әнинең өзелеп елаганын хәтерлим. Ә без бала - чага бик аңлап бетә алмадык. Сугыш башланганда миңа 10 яшь, энем Баязитка 5 яшь, сеңлем Фәнисәгә 3 яшь, Әнисә сеңлем 40 көнлек кенә иде»-дип сүзен дәвам итте Хания Гаяз кызы.

Әтисе сугышка китеп бер ел үткәч, Хания Гаяз кызының картәтисе Шайхетдин карт Уфага килеп аларны бәләкәй арбага утыртып Иске Муса авылына алып кайта.

«… Авылга кайткач торырга урын юк. Әни үзенең әйбәт киемнәрен, әткәйнең киемнәрен сатып бер бәләкәй генә өй сатып алды. Авылга кайткан көннән башлап әни колхоз эшенә тотынды. Әнисе колхозга эшкә китә, өй эшләре һәм өч туганы 10 яшьлек кыз кулына кала. Балаларым ач тормасын дип әниебез төннән төнгә эштә йөреде.Кайчакларда хәлсез кайтып егыла торган иде. Безнең тамак тук булсын дип, күпне күрде әниебез» - дип искә ала Хания Гаяз кызы.

Еллар үтте. Дөнья үзгәрде. Хәзер инде баш өстебездән дошман самолетлары да очмый , җиребезне дер селкетеп танклар да гизми, адым саен бомбалар да шартламый…Тик хәтердә әле ул еллар, хәтердә.



**Фотода : Мөхәммәтдинов Гаяз Шәйхетдин** улы**,** бертуган сеңлесе **Факия Шәйхетдин** кызы(уң яклап),тормыш иптәше **Мәймүнә Мөхәммәтдинова** (сул яклап) һәм басып торганы **Хаерниса (** бертуган энесенең хатыны.)

**Әхмәтшина Хания Гаяз кызы һәм әтисе турында әдәбият**


- **Ахметшина Хания Гаязовна:Справка** // Герои тыла.Списки труженников, награжденных медалью « За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941 -1945 г.г. » т.**17.-** Уфа:Китап , 2010 . – с.41**.**
- **Мухамматдинов Гаяз Шайхетдинович** [отец Ахметшиной Ханий Гаязовны] //Память Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 г.г. Книга 19.- Уфа: Китап , 1999 .- С.396

# *«Тамак төбендәге төер»*

**Кадыров Минулла Гарифулла улы 1927 нче елда Чишмә районының Иске Муса авылында туган. «Сталинчы»колхозында колхозчы булып эшләгән. Бөек Ватан сугышы башланганда 14 яшьлек үсмер малай була.**



« ***Сикәлтәле еллар , чакрымнар –***
***Кече яшьтән миңа якыннар***» – дип башлады сүзен Минулла Гарифулла улы. Безнең әткәйне 1943 нче елны сугышка алып киттеләр. Без алты бала тилмерешеп карап калдык. Кем уйлаган, шул көн -әткәй белән соңгы күрешү дип.

Ашарга накыс, кияргә кием юк. Соңгы атларны сугышка алып беттеләр. Иген урыр чак җитте. Ат урынына без 13-14 яшьлек малайлар.Ике кешегә бер косилка иде. Басу тулы кеше, кем кул урагы белән иген ура, кем көлтә бәйли, олысы –кечесе бар да эштә булды. Кыр эшләре беткәнче басуда кунып ятабыз. Кичләрен уен –көлке белән әзрәк күңел ачып алабыз.Олы апалар әкрен генә озын көйгә җыр башлыйлар:

Сагынырсыңмы диеп сорыйсың да
Башың иеп борылып китәсең.
Киткән юлларыңа карый – карый
Сыкрый – сыкрый җылый йөрәгем.
Өзелә дә инде минем үзәгем...



Шул җырны җырлаганда ниләр уйлады икән ул апалар. Күпме сагыш, күпме әрнүле күз яшьләре акты ул елларда.

Авылдан ир –егетләрне сугышка әкренләп алып беттеләр. Безгә чират җитте. 14-15 яшьлек усмер малайларны « Кымыз промга» армиягә алыр өчен әзерлек мәктәбенә җыйдылар. Анда безне сугышырга, окоп казырга өйрәттеләр.

... Бер көнне авылга 25 ат куып китерделәр. Бу әсирлеккә эләккән дошман атлары булып чыкты. Менә шул атларны җигеп « Шөнгәк күл» станциясенә иген ташыдык.»

Сугыш …

Бу сүзне ишеткәч тә, күз алдына коточкыч вакыйгалар, Туган илне дошманнар кулына бирмәс өчен киткән һәм яңадан әйләнеп өйләренә кайта алмаган ирләр, уллар, аларны өзелеп көткән ялгыз аналар, тол хатыннар, сабый балалар килеп баса. Минулла Гарифулла улы да үзенең газиз әтисен күрә алмый, ул яу кырында үлеп кала.

**Кадыров Минулла Гарифулла улы һәм әтисе турыда әдәбият:**


- **Кадыров Минулла Гарифуллович: Справка** //Герои тыла.Списки труженников, награжденных медалью « За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941 -1945 г.г. » т.17.-Уфа : Китап , 2010 . – С.160

- **Кадыров Гарифулла Тагирович** [отец Кадырова Минуллы Гарифулловича] //Память Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 г.г. Книга 19.- Уфа: Китап, 1999.- С. 364.

*«Тынгы бирми көн дә шул яралар ,*
*ә күпме ел ята арада»*



**Кадырова Тәнзилә Гайзетдин кызы.**
**1928 нче елны Чишмә районының Иске Муса авылында туган.**
**«Коммунизм» колхозы колхозчысы.**

... 1941 ел 22 июнь.
Бу көн мәңге онытылмас яра салды халык йөрәгенә.
4 ел. 1918 көн. 34 мең сәгать һәм 27 миллион һәлак булган кеше гомере... Ә күпме әниләр–улсыз, балалар-әтисез калган.

«... Бертуган абыем **Фасхутдинов Минислам Гайзетдин** улы 1917 нче елда туган. 1939-1940 нчы еллардагы фин сугышында катнаша. 1940 елның ноябрь азакларында фин сугышыннан кайткач военкоматка чакырталар. Военкоматтан **Минислам Гайзетдин** улын Уфага развед школага укырга җибәрәләр. 1941 нче елның язында укуын бетереп кайта. Язгы кыр эшләрендә катнаша. Чәчү эшләре тәмамланган иде инде, бер дә көтмәгәндә сугыш башланды. Бу хәбәр,чалт аяз көнне яшен яшьнәгән кебек булды. Сугышның икенче көнендә ук **Фасхутдинов Минислам Гайзетдин** улына һәм тагын өч кешегә чакыру кәгазьләре килде. Аларны атка арба җигеп озатырга булдылар. Ләкин басу капкасын да чыгарга өлгермәделәр, арбаның күчәре сынып килеп төште. Аны тиз генә алыштырдылар да, юлга кузгалдылар.



Шул чак абыем ,**Минислам Гайзетдин** улы нәрсәдер сизенгәндер күрәсең:« Без кабат әйләнеп кайта алмабыз инде» –дип әйтеп куйды. Шул китүдән аны кабат күрә алмадык. Абыем **Минислам Гайзетдин** улы турында шуларны гына беләм.Ул разведчик була.1942 нче елда Минислам Гайзетдин улына һәм тагын алты разведчикны дошман тылына заданиегә җибәрәләр. Алар Волга елгасын кисеп чыгарга тиеш булалар. Шул заданиедә хәбәрсез югала.

Тәнзилә Гайзетдин кызының икенче абыйсы **Фасхутдинов Гайнислам Гайзетдин улы** , 1941 нче елда, сугышка тиклем Каменск Подольский районындагы хәрби частьтә хезмәт итә. Шул елда ук хәбәрсез югала.

Дәһшәтле сугыш... Бу ике сүз нинди коточкыч мәгънәгә ия. Аяусыз сугыш еллары кешегә күпме кайгы –хәсрәт,югалту ачылары, авырлык- кыенлыклар китерде.

**Кадырова Тәнзилә Гайзетдин кызы һәм абыйсы турында әдәбият:**


- **Кадырова Танзиля Гайзетдиновна:Справка** //Герои тыла. Списки труженников, награжденных медалью «За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941 -1945 г.г. » т.17.-Уфа:Китап, 2010.- С.161.

- **Фасхутдинов Гайнислам Гайзетдинович**[брат Кадыровой Танзили Гайзетдиновны] //Память. Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 г.г. Книга 19.- Уфа:Китап, 1999.- С.432.




# *«Әтисез бик авыр булды»*



**Кәримова Суфия Мәһәди кызы.**
**1932 нче елда Кырмыскалы районының Атҗитәр авылында туган. Сугыш башланганда Суфия Мәһәди кызына 9 яшь була.**

«... Сугыш чыккан дигән хәбәрне урамда ишеттем . Иптәшләрем белән урамда уйнап йөргән вакытта хат ташучы миңа этиеңә бирерсең дип бер бәләкәй генә кәгазь калдырып китте. Анда нәрсә язылганын да белмичә, эти янына йөгереп бардым.Тик ул эшендә юк иде. Әтине Мәскәүгә командировкага җибәргәннәр. Икенче көнне эти Мәскәүдән кайтты да туры военкоматка китте. Шул китүдән эти бүтән кайтмады.» - дип сөйли Суфия Мәһәди кызы.

«... Авыр тормыш юлына бик иртә басарга туры килде шул безгә.Бөтен авыр эш без бала – чага, хатын – кыз һәм олы яшьтәге бабайлар иңенә калды. Иген утыйбыз, шуннан печән өсте җитә.Урак вакытында әниләр урак белән иген ура, без көлтә бәйлибез. Аннан күбәгә утыртабыз , кипкәч эскерт салабыз. Көзгә аны сугабыз. Өч ат җигеп молотилканы әйләндерәләр. Өч малай ат куып тора. Без кызлар саламын алып торабыз. Икенче кешеләр эскерткә өя. Көч җитми, көлтә күтәргән килеш егыла идем.

Булган атларны сугышка алып киттеләр. Сыерларны җигеп җир эшкәртә идек.

Кышкы суыклар бик үзәккә үтә торган иде. Әнигә ярдәм булыр дип урманга утынга да йөрдем. Утынга качып кына барабыз, урман каравылчысы күреп калса, утынны бушаттыра иде. Утынга барып кайткач, әни тимер мичне кабызып җибәрә. Өй эченә җылы йөгерә . Шунда бер –ике бәрәңге тәгәрәтә иде. Бигрәк тәмле булып пешә инде бәрәңге, ашап туймаслык.

Язга чыккач кешеләр башак җыярга яланга баралар. Көздән кар астында калган башакны ашап, агуланып үлүчеләр дә бик күп булды»





# «Сугыш безгә заман авырлыгын күтәрергә өйрәтте»



**Максютова Тагъзимә Нәби кызы.**
**1932 нче елда Чишмә районының Тәпәреш авылында туган. «Сталинче» колхозы колхозчысы.**

«...Сугыш башланганда миңа нибары 9 яшь иде. Безнең әткәй Хәйруллин Нәбиулла Нагимулла улы 1942 нче елда сугышка китте. Ул вакытта без Иске Муса авылында яши идек. Без дүрт бала әткәйне сугышка озатып калдык.Сугыштан безнең әти контужен булып кайтты. 1947 нче елның 25 сентябрендә алган яраларынан вафат булды.

...Сугыш вакытында әни колхозда эшләде. Мин әни кайтуга тимер мичне ягып ашарга пешерәм. Буй җитми, шуңа утын түмәренә менеп басып аш сала идем.»- дип искә ала Тагъзимә Нәби кызы.

**Максютова Тагъзимә Нәби кызы турында әдәбият:**

· **Максютова Тагзима Набиевна:Справка** // Герои тыла. Списки труженников , награжденных медалью «За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 г.г.» т.17.-Уфа:Китап, 2010.- с.207.



# «Тамак туйганчы ашарга ипи булмады»



**Масалимова Фәридә Минигалим кызы. 1934 нче елда Чишмә районының Яңа Муса авылында туган. Сугыш башланганда нибары 7 яшьтә генә була.**

Бөек Ватан сугышы авырлыклары безнең- сугыш еллары балаларының йөрәкләренә кара кан белән язылган инде. Сугыш бездән яшьне сорап тормады, колаклардан тартып ...гел, төпкә җикте .

Ул елларны Фәридә Минигалим кызы болай дип искә ала.



«...Әниләр кичләрен җыелышып кич утыра торган иделәр. Сукыр шәм астында фронтка җибәрергә оек, бияләй, мылтык бияләе ( өч бармаклы бияләй) бәйлиләр. Без бала- чагалар да шунда йон эрләшергә булышабыз. Аннан вак кына итеп бәрәңгене турыйбыз да тезеп мичкә киптерергә куябыз. Бәйләгән әйберләрне, киптергән бәрәңгене килеп алып китәләр. 1942 -1943 нче елларда бик авыр булды. Ашарга юк, кияргә кием дә юк. Җәй көне укулар беткәч, чүгендер утарга йөрибез. Борчак өлгергәч, борчак җыябыз.Әниләр урак белән уралар, без бала-чага кәбәнгә салабыз.



Күз җиткәч яланга башак җыярга барабыз. Аякта чабата.Чабатаны әни үзе үрә иде.Тула оек баса иде.

Чабата белән тула оек киеп урманга утынга барабыз.
Утын дигәне шул читләвек чыбыгы инде. Аны күп күтәреп булмый, авыр. Урман каравылчысы күрмәсен өчен утынга төнлә ай яктысында барабыз.
... Уку булмады инде. Авылыбызда бер мәчет бар иде. Шул мәчетне бетереп мәктәп ясадылар. Укырга берничә кешегә бер китап, язарга дәфтәр юк, мич корымыннан язарга кара ясыйбыз.
... 1943-1944 нче еллар булгандыр - дип сүзен дәвам итә Фәридә Минигалим кызы, авылыбызга Мәскәүдән эвакуация буенча бик күп кеше килде. Балалар күп иде. Аларны буш йортларга, кешеләргә яшәргә керттеләр. Аларны «Мәскәүлеләр» дип йөртәләр иде. «Мәскәүлеләр» урам буйлап ашарга соранып йөриләр иде. Тамак туйганчы ашарга ипи булмады. Бер елга йорт башына 7 килограмм он бирәләр иде. Менә шуны җиткерегә тырышабыз.
Үзебез гаиләдә әни белән бишәүбез. Җәй буена сарык көтүе көтә идек. Көтүгә барабыз, ачыккач берәр сарыкны савып сөтен эчә идек.
...Бертуган апам Байза Минигалим кызын Стәрлегә мобилизациялиләр, траншеялар чокыйлар. Кыз бала өчен бик авыр була. Аннан ул бер кыз белән качып кайта. «Машина тавышы чыкса иген арасына качабыз»- дип сөйли иде Байза апа дип искә ала Фәридә Минигалим кызы. Шулай качып кайтып керәләр кызлар туган өйгә. Ләкин икенче көнне үк эзләп килеп, кабат алып китәләр

# «Әти солдат була»

**Мирхәйдәров Газзәли Муллагали улы. 1936 нчы елның 13 апрелендә Чишмә районының Иске Муса авылында туган. Сугыш башланганда 5 яшьтә була.**

Сугыш…

Нинди коточкыч, тетрәндергеч сүз. Ул еллар беркайчан да онытылмас. Дошман туган җиребезгә басып керде.

1941 нче елның 22 июнь иртәсе иң матур җәйге көннәрнең берсе иде, ләкин ул безнең өчен зур кайгы китергән таң булды.

«... Балалык белән сугышның ни тиклем зур бәлә икәнлеген баштарак аңлап та бетермәгәнмендер. Безнең әткәй, Муллагали Минияр улы сугышка киткән көнне мин, биш яшьлек малай: «Минем әткәй солдат була»-дип ура кычкырып агач атка атланып сикергәләп йөргәнмен. Соңырак, үсә төшкәч аңладым, әнинең ни өчен өзелеп елаганын да, әткәйнең моңсу карашын да, ләкин соң булды.

1942 нче елның сентябрь аенда әтинең үлү хәбәре килде.

... Сугыштан соң бик озак еллар үткәч кенә әтиебез Мирхайдаров Муллагали Минияр улының Чечен республикасындагы Орджаникидзе районының Ищерск станциясында куелган «Братская могила» га күмелгән икәнлеген белдек»- дип сөйләде Мирхәйдәров Газзәли Муллагали улы .

**Мирхәйдәров Газзали Муллагали улының әтисе турындагы әдәбият:**


· **Мирхайдаров Муллагали Миниярович** [отец Мирхайдарова Газзали Муллалаглиевича] // Память.Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.Книга 19.-Уфа: Китап,1999.-С.391.

# *«Кошлар ашыйсы җимнәрне ашап, гомерне озайттык»*



**Насретдинова (Ахмадиева) Хания Хабибулла кызы. 1932 нче елда Чишмә районының Абрай авылында туган. Сугыш башланганда 9 яшь була.**

«…1941 нче елның 5 сентябрен дә безнең әти сугышка китте. Без өч бала калдык. Әнинең бар ышанычы без, балалары идек. Миңа 9 яшь, энем Вәзиткә 3 яшь һәм әти сугышка киткән көнне кечкенә сеңлем Садия дөнъяга аваз салды.
Киярргә кием накыс булды. Ашарга да җитмәде. Төрле хәлләр булды, ләкин берсе хәтердә бик җуелып калды, дип сөйли Хания Хабибулла кызы.

«… Бер көнне шулай кызлар җыелышып качып кына башак җыярга бардык. Көн озыны башак җыеп кайтырга чыккан идек, каршыга «Тупык Масун» кушаматлы кеше килеп чыкты. Безне туктатты, капчыкларны тарткалап җыеп алды да күпер төбеннән елгага башакларны бушатып суга агызып җибәрде. Буш капчыкларны кочаклап, елаша-елаша кайтып киттек.

…Шулай тагын биш кыз «Новокиевка» яланына  кыштан калган бәрәңге җыярга бардык. Саздан җыйган бәрәңгене яланда аккан суда юабыз. Су салкын, үзәкләргә үтә салкыны, куллар кызарып күгәрчен тәпие кебек күм-күк булды. Флюра исемле әхирәтемнең такмаклап елаганы бүгенгедәй исемдә: «Өшемәче, кулыкаем, бәрәңгене юарга кирәк». Бәрәңге юганда Хания Хабибулла кызын да су ташкыны агызып алып китә. Аны күреп калып Рәкәй исемле абзый коткара.
Сугыш елларында күргән газапларын искә алып:«Кошлар ашыйсы җимнәрне ашап, гомерне озайттык» -дип әйтеп куя Хания Хабибулла кызы

**Насретдинова Хания Хабибулла кызы һәм этисе турында әдәбият:**

·**Ахмадиев Хабибулла Гиниятуллович**[отец Насретдиновой Ханий Хабибулловны] //Память Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 г.г. Книга 19.-Уфа : Китап, 1999.- С.306.
·**Насретдинова Хания Хабибулловна: Справка** //Герои тыла.Списки труженников, награжденных медалью «За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941 -1945 г.г. » т.17.-Уфа:Китап,2010.–С.238.



# «Колхоз аты йончып үлсә, шуның итен бүлешеп алдылар »



**Салихов Мөнир Миннулла улы. 1933 нче елда Чишмә районы Иске Муса авылында туган. Сугыш башланганда аңа бары тик 8 яшь була.**

«...Балалык белән сугышның ни тиклем зур бәла икәнлеген баштарак аңлап та бетермәгәнбездер.Тик үз җилкәбездә татый да башладык. Хатын – кызлар, әниләр елашып ирләрен, улларын сугышка озатканнары, аларсыз бушап, җимерелеп калган авылыбыз күренеше, күрше – тирә, танышларга, туганнарга килә башлаган кара кайгы хатлары, шуларга бәйле күңелгә уелып калган кайгы – хасрәт, курку, пошыну тойгылары гомергә онытылырлык түгел.

«… Бик авыр вакытлар» - дип сүзен дәвам итә Мөнир Миннулла улы. Кияргә кием юк, тамакка ашарга юк-черек бәрәнге, алабута, кечерткән һәм су иде. Әниләргә, олы апаларга ияреп иген утарга йөрдек, тырмада да булдык . Ун малай – ун пар ат җигеп тырмада йөрибез. Күрше авыл «Романовка» басуына барып кар астында калган башакларны җыя идек

«Романовка»- урыс авылы, бик усал халык, күреп калсалар ат менеп куалар иде. Шуңа күрә  кача-поса гына бара идек. Ул елларны маллар да бик күп үлде, ачтан. Булды шундый хәлләр,үлгән  хайван итләрен дә ашады халык. Сугыш  бетте дигән хәбәрне басуда тырмада йөргәндә  ишеттек. Берәү ат менеп килә. Үзе: «Сугыш беткән! Сугыш беткән!» дип кычкыра. Миннән ике яшькә олы, күрше малае Шарафутдинов Фәритне ат мендереп, 6-7 чакрым ераклыкта булган «Новокиевка» авылына «Сугыш бетте!» дигән хәбәрне әйтергә  җибәрделәр.

Тик ул хәбәргә без ышанып бетә алмадык. Дурт ел буена барган сугыш, дурт ел ач –ялангач яшәп, күп авырлыклар  күтәргәч бу көнне без күрербез дип ышанмаган идек. Сөйләп бетергесез ул  көн. Кемнәрдер яу кырында ятып калган улларын, ирләрен, туганнарын  сагынып ,  юксынып үксеп елады, кемнәрдер шатланды, кемнәрдер моңсу гына офыкка карап якыннарының  кайтуын өмет итте.

Сугыш бетте,әмма без сугыш балалары куңелендә яралар төзәлерлек түгел, бүген дә шулар үзәкне өзә.

Мөнир Миннулла улының  хатирәсен исбат итеп  Башкортостан язучысы Әнгам Атнабаевның «Без-егерме сигезенчеләр» исемле шигыре искә төшә:



***«...Сугыш безне, колаклардан тартып,***
***Вакытыннан алда өлгертте:***
***Кичтән егет итеп йоклатты да***
***Хәле бетеп тынган дулкын сыман,***
***Таң атуга инде ир итте.***
***Сугыш безгә килеп тукталды.***
***Яшь йөрәкләр ярсу ат шикелле***
***Шома юлдан гына атламадык,***
***Яу кырына карый укталды...***
***Сикәлтәле булды юлыбыз***
***Сугыш безгә килеп тукталды.***
***Сталинны « бөек ата» диеп,***
***Әтиләрсез үскән буын** без...»*









# *«Сугыш беткәнче торф кистек»*



**Фәхретдинова (Зарипова ) Фәһимә Вәлимһәмәт кызы. 1928 нче елда Чишмә районының Иске Муса авылында туган. «Сталинчы» колхозында колхозчы булып эшләгән. 1941 нче елда Фәһимә Вәлимһәмәт кызына нибары 13 яшь була.**

«...Җәйнең иң матур көне иде. Печән өсте. Бар халык, олысы – кечесе яланда печән җыя. Без бала- чагалар тырматкан булабыз, зурыраклар эскерткә өяләр. Көннәр матур торганда печәнне җыеп бетерергә кирәк. Шул чак авыл ягыннан бер атлы күренде. Шау–гөр килеп торган басу кинәт тынып калды. Ниндидер хабәр көткәндәй бар да атлы кешегә төбәлделәр. Атлы кеше ( исемен хәтерләми ) «Сугыш чыккан! » – дип әйтте. Йөрәк өшеп куйды бу хәбәрдән. Ни эшләргәдә белмәдек.Шаулап торган басу кырында сәер тынлык урынлашты. Әйтерсең дә кояшны кара болыт каплады. Бөтен дөнья караңгыланган кебек тоелды. Әниләр, әткәйләр, апалар, кызлар, малайлар,әби – бабайлар барысы да башларын аска иеп эшләрен дәвам иттеләр.

Икенче көнне военкоматтан чакыру кәгазьләре килә башлады. Иске Муса авылы егетләре чалгыларын винтовкага алыштырды. Безнең әтине, Зарипов Вәлимһәмәтне хезмәт армиясенә алдылар.

...1942  нче елның кышында мине һәм тагын 5 кызны «Марусино» урманына агач кисәргә ярдәмгә җибәрделәр. Аннан соң «Баскак»урманында агач кисеп йөрдек. Кыш салкын, кигән кием дә йока гына. Аякта тула оек, чабата. Кар бигрәк тирән , батып калабыз. Хәлдән язып кайтып егыла торган идек.



Кеше җитмәгәч, безне, берничә кызны, совхоз аръягына торф кисәргә җибәрделәр. Бик авыр иде торф кисәргә. Кул көрәге белән 4025 кирпич кисәргә тиешбез.
 План бирәләр иде.Шул планны тутырсаң, 800 грамм ипи бирәләр..

...Сугыш беткәнне дә торф кискәндә ишеттек.Эй куандык инде. Флаглар күтәреп каршы алдылар, балык башыннан аш пешергәннәр иде. Шул көнне тәү башлап җылы аш күрдек . Тамак туйды әллә шатлыктан, әллә балык ашыннан»- дип хатирәләре белән уртаклашты Фәһимә Вәлимхамәт кызы.

**Фәхретдинова( Зарипова ) Фәһимә Вәлимхамәт кызы турында әдәбият:**


- **Зарипова  Фагима Валимхаматовна: Справка**  // Герои тыла.Списки труженников , награжденных медалью « За добросовестный труд в Великой Отечественной войне 1941 -1945 г.г. » т.17.-Уфа : Китап , 2010 . – С.138 .

# «Аяксызга - аяк, кулсызга – кул, күзсезгә күз булдык»



**Хәммәтдинова Халилә Ибраһим кызы.**
**Тыл ветераны. 1923 нче елда Чишмә районының Чувалкип авылында туган. Сугыш башланганда 18 яшьтә була. Иске Муса авылында яши.**


«...Сугыш елларында мин хат ташучы булып эшләдем. Муса авылына килеп почта ала идек. Язгы ташкын вакытында Кизәк елгасы аша чыкканда чабатаны чыланмасын дип салып кулга тотып чыгабыз. Су салкын аяклар өши, тоймы башлый иде. Елганы чыгу белән чабатаны киеп алабыз. Кабат әйләнеп кайтканда тагын шулай чабатаны салып ялан аяк салкын су аша чыгабыз.Чабатаны туздырасы килми, чөнки бүтән аякка кияргә аяк киеме юк. Бик авыр булды дип искә ала сугыш елларын Халилә Ибраһим кызы, тамакка ашарга да юк, кияргә кием дә булмады. Сугыш чорында укый, яза белгән халык бик әз булды. «Кемгәдер хат язарга булышам, кемгәдер укып ишеттерәм»- дип искә ала Халилә Ибраһим кызы.

Сугыштан соң 1947 нче елда Иске Муса авылы егете Мөхетдин исемле егеткә тормышка чыга. Колхоз эшләрендә йөри. Тормыш иптәше Мөхетдин Сәләхетдин улы белән алты бала тәрбияләп үстергәннәр. Бүгенге көндә Иске Муса авылында улы һәм килене тәрбиясендә көн күрә.



Ибраhим кызы.

Сугыш корбансыз булмый. Сөйгәннәребезне көтеп ала алмадык. Кайтканнары да гарип – гөрәбә иде. Аяксызга –аяк, кулсызга –кул, күзсезенә күз булдык дип сүзен тәмамлады Халилә Ибраhим кызы.



**Хәммәтдинов Мөхетдин Сәләхетдин** улы .

(Хәммәтдинова Халилә Ибраhим кызының тормыш иптәше) 1923 нче елда Иске Муса авылында туган.

нче елда армия сафына алынаСугышның беренче көненнән үк яуга керә.

Сталинград сугышында каты яралана, госпитальгә эләгә. Госпитальдә савыгып чыкканнан соң тагын сугышка китә. Днепрны кичүдә катнаша.

Сугыштан соң колхозда бригадир булып эшли,соңрак урман каравылчысы була. Сугыш бетүе бирәүләргә куаныч булса,әтиләре, ирләре, уллары үлеп калганнар өчен бетмәс кайгы китерде. Ул көндәге хис –тойгыларны сүз белән генә аңлатып бетерерлек түгел. Бәхет тә, хәсрәт тә иде кешеләрнең йөзләрендә.

**Хәммәтдинов Мөхетдин Сәләхетдин улы турында әдәбият:**


- **Хамматдинов Мухетдин Салахетдинович**[муж Хамматдиновой Халили Ибрагимовны] //Они вернулись с Победой. Списки военнослужащих,вернувшихся живыми с Великой Отечественной войны 1941-1945гг.Т12.- Уфа: Китап,2005.- С.337.

# «Без ятимнәргә көн булмады»

**Шарафутдинова Флүзә Минигази кызы. 1942 нче елда Чишмә районының Кызылгы авылында туган.**

«...Әткәй сугышка киткәндә мин әнинең карынында булып калганмын. Шуңа да әткәйне әни сөйләгәне белән генә күз алдыма китереп бастырам. Яу кырыннан әткәйнең 4-5 хаты килгән, аннан соң ***«1943 нче елның ноябрь аенда кызыл армеец Баширов Минигази Хисаметдинович хәбәрсез югалды»-*** дигән кара кәгазь килгән.

Тарихыбызда булып узган бар сугышларның да иң авыры –бөтен дөньяны тетрәткән һәм халкыбыз язмышында тирән эз калдырып үткән Бөек Ватан сугышы бервакытта да онытылмас.

Ирләр китә ... Аларның урынына хатын -кызлар, карт- коры, буыннары да ныгынып өлгермәгән балалар баса... Солдатларны ризык, кием, корал белән бер туктаусыз туплап торырга тырыштылар. Көнне – төнгә ялгап эшләделәр.

Флүзә Минигази кызының әнисе Бәширова Миңкәй язып калдырганнар буенча :

«...***Без ятимнәргә көн булмады. Сугыш елларында күрмәгәннәр калмады инде. Сугыш тәмамлангач та , сугыштан кайткан абзыйлар хуҗа булды дөньяга. Без ятимнәргә көн юк. Сарык каравылларга куйдылар.Төнлә бүреләр кереп, сарыкларны яралап чыгып киттеләр. Барырга курыктым. Аннары сыерны сатып түләдем. Карап торган мал иде. »- бу хатирә «Кызыл таң »газетасында басылып чыкты.***

*( Бәширова М. «Озын сүзнең кыскасы» //Кызыл таң .-2001 ел.-10 июнь)*

Сүзен дәвам итеп Флүзә Минигази кызы «... әнинең елап сөйләгәне әле дә күз алдымда : ...күлмәк итәген ат тарткалаганга уянып киттем. Торып карасам сарыклар канга тузып яталар. Бүреләр хөҗүм ясаганнар иде. Икенче көнне сыерны алып киттеләр. Капка төбендә тилмерешеп карап калдык. Абрай авылы мәктәбендә укытучы булып эшләгән Богданов Шамсулла Кәшфи улы Мәскәүгә хат яза. Бер аз вакыт үткәч хатка җавап килде. Шул хатта сыерны хуҗасына кайтарып бирергә диелгән иде. Ләкин сыерны кайтаручы булмады.»

Күпне күргән, күпне кичергән Баширова Миңкәй тормыш авырлыгына бирешми, матур – матур шигыйрьләр язып калдырган.

Менә шуларның бер ничәсе:

*1.* Ятсам да йоклый алмыймын
Сандугачлар уята.
Сайраган булып юата,
Бәхетең юк дип елата.

2. Җир җиләген бик күп җыйдым
Савытларым тулмады.
90 ел гомер кичердем
Тугыз ай да булмады.

3 ..Алтын йөзекләр койдырдым,
Үлчәп карап зурлыгын,
Кабрем өстенә чәчегез
Бу чәчәкнең орлыгын.



4. Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миңнекәй,
Тасбих әйтеп чәчкә чәчтем
Каберемнең өстендә.



**Фотода: Чишмә районының Кызылгы авылы тыл ветераннары( уңнан сулга) беренчесе Бәширова Миңкәй, Нуриманова Хабибә, Баширова Әклимә, Асфандиярова Гөльсөм, Асфандиярова Габидә. 1978 ел.**

**Шарафутдинова Флүзә Минигази кызының әтисе турында әдәбият:**

· **Баширов Минигази Хисаметдинович[**отец Шарафутдиновой Флюзы Минигазиевны**]** //Память Списки погибших в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 г.г. Книга 19.- Уфа: Китап,1999.-С.316.

Помним Гордимся

# « Көмөш миҙалдар»

«Ҡулъяулығына төрөп  һаҡлай
Әсәкәйем көмөш миҙалдарын,
Алтындарҙан артыҡ  күрә уны,
Күргән өсөн тормош ыҙаларын.

Көмөш миҙалдарҙың көмөштәре
Күскән,әсәй, күптән сәстәреңә.
Ауырлыҡтың алдың иң хәтәрен,
Ҡарамайса үҫмер йәштәреңә.

Бүләк, миҙал өсөн эшләмәнең,
Бар бәхетең менән риза булдың.
Йөрәгеңде хәсрәт ялмаһа ла,
Илең өсөн йәнең фиҙа ҡылдың... »

Ҡәҙим Аралбай





...Их, әсәләр, һугыш йылдарында
Теңкәгеҙгә тейҙе ауырлыҡ,
Заман  ауырлыгын күтәрергә,
Яу кайгыһын  баштан үткәрергә,
Ҡайҙан  тылсымлы көс таптыгыҙ  ҙа
Кайҙан алдығыҙ  һуң сабырлыҡ.
Былбыл  һайрауҙарын тыңлар саҡтар
Һеҙ  бит сабаталар үрҙегеҙ.
Сабаталар үреп кейҙегеҙ  ҙә
Алабута баҫкан яландарҙа
Һыер егеп һабан һөрҙөгөҙ!

*Абдулхаҡ Игебаев.*


© otkrytka.eu

**Хәзерләде :**
**Чишмә районы Иске Муса авыл китапханәсенең алып баручы китапханәчесе Әхмәтшина К. М.**
**апрель, 2020**